**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«25» март 2020 ел № 56/4

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 4.1 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Әҗмәкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Р.Ф.Адиев

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советының 2020 елның 25 март 2020 ел. 56/4 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген (алга таба – исемлек) формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару процедурасын билгели.

2. Исемлеккә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Әҗмәкәй авыл җирлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган, муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында яки муниципаль учреждениеләргә оператив идарә итү хокукында беркетелгән, шулай ук өченче затларның башка хокукларыннан азат булган, Тукай муниципаль районы казнасы мөлкәте булган күчемле һәм күчемсез милек, шул исәптән җир кишәрлекләре, биналар, корылмалар, төзелмәләр, торак булмаган биналар, җайланмалар, машиналар, механизмнар, җайланмалар, махсус транспорт чаралары кертелә.

3. Исемлеккә кертелгән мөлкәт бары тик кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга, шул исәптән арендага бирү максатында гына файдаланылырга мөмкин һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган һәм

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арендага ала торган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы 2.1 өлеше нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләүле нигездә читләштерелергә мөмкин.

4. Исемлектән милекне төшереп калдыру түбәндәге очракларда башкарыла:

- исәптән чыгару;
- милекне югалту (һәлакәт);
- милекнең сан һәм сыйфат характеристикаларын үзгәрү, нәтиҗәдә әлеге мөлкәт үз билгеләнеше буенча файдалану өчен яраксызга әверелә;
- мөлкәтне билгеләнгән тәртиптә федераль милеккә, Татарстан Республикасы милкенә, Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре милкенә тапшыру;
- муниципаль ихтыяҗлар өчен әлеге милеккә ихтыяҗ барлыкка килү;
- муниципаль милекне арендалау шартнамәсен төзү хокукына өч тапкыр аукцион (конкурс) үткәрү, аларны үткәрү нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнар нигезендә аренда шартнамәләре төзелмәгән. Бу милеккә карата аны алга таба файдалану буенча идарә карары кабул ителә.

5. Милек исемлеге һәм аңа үзгәрешләр кертү Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән раслана.

6. Исемлек Россия Федерациясе Икътисадый үсеш Министрлыгының «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законның 18 статьясы 4 өлешендә күрсәтелгән дәүләт милкенең һәм муниципаль милекнең расланган исемлекләре турында, шулай ук мондый исемлекләргә, «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча федераль корпорация» акционерлык җәмгыятенә кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 елның 20 апрелендәге 264 номерлы боерыгында билгеләнгән форма буенча кәгазь һәм электрон чыганакларда вәкаләтле орган тарафыннан алып барыла.

7. Исемлек һәм аңа кертелә торган үзгәрешләр «Якты юл» («Светлый путь») матбугат басмасында, шулай ук «Интернет» челтәрендә вәкаләтле орган тарафыннан Исемлек расланганнан яки аңа үзгәрешләр кертелгәннән соң, 10 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.